Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуны оештыру турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясына таянып, Чүпрәле районы прокурорының 2020 елның 09 июнендәге № 02-01-16-2020 таләбен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 23 сентябрендәге 548 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуны оештыру турында" Нигезләмәгә, түбәндәге эчтәлекле 8.2 пунктын өстәп, үзгәреш кертергә:

«8.2. Ташучы тарафыннан билгеләнгән тарифтан 50 процентлы ташлама рәвешендәге транспортта йөрү өчен ташлама түбәндәге категория гражданнарга билгеләнә:

- 60 яшькә җиткән хатын-кызлар өчен, 65 яшь - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә урнашкан ир-атлар өчен, шәхесен таныклаучы документ күрсәткәндә;

- «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Мактаулы гражданы» исеменә лаек булган гражданнарга-исеме булуын раслаучы таныклык биргәндә;

- тәрбияләрендә инвалид балалары булган гражданнарга;

- тәрбияләрендә 3 һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарга.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше буенча бүлек начальнигы Р. Р. Баһаутдиновка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов